Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе турында

Россия Федерациясе Президентының «Сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча өстәмә чаралар турында» 2015 елның 23 гыйнварындагы 31 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручының 2015 елның 09 маендагы ПУ-431 номерлы Указын үтәве турында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору буенча комиссия төзергә һәм аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе турындагы нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе эшчәнлеген, шул исәптән Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнеше өлкәсендәге вәзгыятьне мониторинглауны гамәлгә ашыру буенча, оештыру ягыннан тәэмин итүне Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге гамәлгә ашыра дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы И.А. Ракиповка йөкләргә.

Чүпрәле муниципаль
район Башлыгы: А.В. Шадриков

Хәйруллина Э. Ж.
2-20-50

1 нче кушымта
Чүпрәле муниципаль районы
Башлыгының 2015 елның
«__»________ ___номерлы
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Шадриков Александр Валерьевич | Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе, комиссия рәисе; |
| Сибагатов Марат Вячеславович | Чүпрәле районындагы Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Ракипов Илдар Альберт улы | Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге начальнигы, комиссия секретаре; |
| Алиуллов Шәүкәт Әхмәтсафин улы | Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Полюшков Алексей Сергеевич | Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Юсупова Глина Хәмис кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Зеленодол территориаль органы контроль-инспекция бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты (килешү буенча); |
| Сәлахетдинова Венера Марс кызы | Федераль салым хезмәтенең ТР буенча 8 нче номерлы МРИ баш дәүләт инспекторы (килешү буенча); |
| Хәсәнов Артур Илдар улы | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Буа, Тәтеш районнарында территориаль бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Җамалтдинова Резедә Ринат кызы | «Татмедиа» ААҖ филиалы Чүпрәле районы «Туган як» газетасы редакциясе директоры (килешү буенча) |

Гомуми бүлек башлыгы: Г. Ф. Хәлиуллов

2 нче кушымта
Чүпрәле муниципаль районы
Башлыгының 2015 елның
«__»________ __номерлы
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе (алга таба - комиссия) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сәнәгать продукциясен законсыз кертүгә, җитештерүгә һәм аларның әйләнешенә каршы көрәш буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүче орган, шул исәптән контрафакт (алга таба - сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнеше), шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә бу өлкәдәге вәзгыятьне мониторинглауны һәм бәяләүне гамәлгә ашыручы орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив хокукый актлары, сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору буенча Дәүләт комиссиясе карарлары, Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе карарлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

а) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләү, шулай ук аларның иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген оештыру;

б) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

в) Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясе базарындагы вәзгыять турында ел саен докладлар әзерләүдә, шулай ук Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе эше турында докладлар әзерләүдә катнашу;

г) Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы торуга, шул исәптән әлеге әйләнешне профилактикалауга, шулай ук аларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар эшләү;

д) Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген анализлау;

е) сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары белән хезмәттәшлек, шул исәптән тиешле уртак карарлар проектларын әзерләү;

ж) Россия Федерациясе территориясендә сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнеше һәм аңа каршы тору мәсьәләләре буенча бердәм мәгълүматлар банкын кулланып Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнеше өлкәсендәге ситуацияне мониторинглау һәм бәяләү;

з) үз компетенциясе кысаларында Россия Федерациясе законнары нигезендә сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору буенча бүтән бурычларны хәл итү.

5. Үз бурычларын гамәлгә ашыру өчен комиссия хокуклы:

а) үз компетенциясе кысаларында Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген оештыру, координацияләү, камилләштерү һәм бәяләүгә кагылышлы карарлар кабул итәргә, шулай ук әлеге карарларның үтәлешен контрольдә тотарга;

б) Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясенә Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын таләп итә торган тәкъдимнәр кертергә;

в) Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору мәсьәләләрен өйрәнү, шулай ук комиссия карарлары проектларын әзерләү өчен эшче төркемнәр төзергә;

г) федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм башкарма хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм аларның вазыйфаи затларыннан, шулай ук иҗтимагый берләшмәләрдән һәм оешмалардан кирәкле материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга;

д) комиссия эшендә катнашу өчен федераль башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын һәм территориаль органнары белгечләрен, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә.

6. Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне комиссия рәисе башкара.

7. Комиссия үз эшчәнлеген планлы нигездә башкара.

8. Комиссия утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Кирәк булган очракта, комиссия рәисе карары буенча комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

9. Комиссия утырышында аның әгъзаларының булуы мәҗбүри.

Комиссия әгъзасы утырышта булмаса, ул бу хакта комиссия рәисенә алдан хәбәр итәргә тиеш.

Комиссия әгъзасы биләгән вазыйфасы буенча вазыйфаларны билгеләнгән тәртиптә башка вазифаи затка йөкләнгән очракта, комиссия утырышында бу вазифаи зат катнаша (алга таба-комиссия әгъзасы вазыйфаларын башкаручы зат).

Комиссия утырышында комиссия әгъзасы вазыйфаларын башкаручы затның булуы мәҗбүри.

Комиссия әгъзасы һәм комиссия әгъзасы вазыйфаларын башкаручы зат карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия.

Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының яки комиссия әгъзалары вазыйфаларын башкаручы затларның яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

Карала торган мәсьәләләргә карап, комиссия утырышында катнашуга башка затлар да җәлеп ителә ала.

10. Комиссия карары комиссия рәисе кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Комиссия карарларын тормышка ашыру өчен билгеләнгән тәртиптә карауга тапшырыла торган муниципаль норматив хокукый актлар проектлары әзерләнә ала.

11. Комиссия аппаратының төп бурычлары:

а) комиссиянең эш планы проектын эшләү;

б) комиссия утырышларын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итү;

в) комиссия карарлары үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

г) Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнеше өлкәсендәге вәзгыятьне мониторинглау, Чүпрәле муниципаль районында күрсәтелгән өлкәдә вәзгыять үсешенә йогынты ясый торган социаль-икътисадый һәм башка процесслар мониторингы, шулай ук аны яхшырту буенча тәкъдимнәр әзерләү;

д) комиссиянең Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

е) Комиссиянең эшче төркемнәре эшчәнлеген оештыру һәм координацияләү;

ж) комиссиянең эш башкаруны оештыру һәм алып бару.

13. Комиссия эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик тәэмин итүне комиссия әгъзалары башкара.

14. Комиссиянең үз исеме язылган бланкы бар.

Гомуми бүлек башлыгы: Г.Ф. Хәлиуллов